РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
СТАРОТИНЧАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИНЧӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» март 2024 ел № 84-1

ТР Буа муниципаль районы Иске Тинчәле
авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында гавәми хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль норматив актны законнарга туры китерү максатында, Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 февралендәге 3-1 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (13.02.2020 № 19-1, 20.10.2020 № 4-1, 23.11.2020 № 6-1, 23.12.2020 № 8-1, 22.06.2021 № 22-4, 15,07.2021 № 22-4, 06.02.2023 № 66-2, 07.04.2023 № 69-2, 08.06.2023 № 73-1, 27.06.2023 № 75-1 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 бүлектә:

а) 7.3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Нигезләмәнең 7.9 пунктында каралган анкета;»;

б) 7.4 пунктны «Мәгълүмат» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләре белән тулыландырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 7.9 пункты белән тулыландырырга:

«7.9. Граждан муниципаль хезмәткә кергәндә анкета тәкъдим итә.

Муниципаль хезмәткәр яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә. Анкета формасы, шул исәптән анда кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

Анкетада булган мәгълүматлар яллаучы (эш бирүче) вәкиле яки аның вәкаләтлесе карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, запрослар җибәрү юлы

белән башкарыла. Гавәми хакимияте органнары һәм тиешле мәгълүматка ия булган оешмалар соралган мәгълүматны әлеге сорауны алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.».

1.2. 16 бүлектә;

а) 16.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 нче пункт белән тулыландырырга:

«12) әлеге Нигезләмәнең 7.9 пунктында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш).»;

б) 16.3 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яки) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яки) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулаучы чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру,яки муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яки) мәгълүматлар тапшырмау;».

1.3. 18 бүлектә:

а) 18.5 пунктын «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

б) 18.7 пунктын «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

1.4. 19 бүлектә:

а) 19.6 пунктында « дөрес булмаган яки» сүзләрен төшереп калдырырга «, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 19.6.1 пункты белән тулыландырырга:

«19.6.1. Муниципаль хезмәткәрләргә 19.6 пунктында күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

1.5. 24 бүлектә:

а) 24.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 2 нче абзац белән тулыландырырга:

«Әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү коррупциягә каршы тору турында Федераль законның 13 статьясының 3 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар тикшерүе тарафыннан танылу очрагында муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы Федераль закон, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнар белән билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.»;

б) 24.3 пунктындагы 1 пунктчаны «яки «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль законның 13.4 статьясына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан» сүзләре белән тулыландырырга.

1.6. 30 бүлекнең 30.1 пунктында 4 пунктчада «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

1.7. 30 бүлектә:

а) 30.1 пунктның 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

б) 30.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пунктчасы белән тулыландырырга.

«11.1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән формада кертүне рәсмиләштерү;».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң законлы көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Иске Тинчәле
авыл җирлеге башлыгы С.Р. Хәсәнов